ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К.Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail: ojm@tatar.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан ш. Боерык

08.04.2022 № 81 - од

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының «Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 346-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында

боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының «Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 346-од номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 04 июнендәге 164-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 258-од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 291-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе

законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

преамбуладагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2002 елның 28 февралендәге 175 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымта итеп бирелгән Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга».

2. Күрсәтелгән боерык белән расланган, Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 346-од номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 08.04 81-од номерлы боерыгы редакциясендә) расланган

# Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының аерым саклана торган төбәк әһәмиятендәге табигый территория чикләрендә («Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 3[1] статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – Регламент, дәүләт хезмәте).

1.2. Гариза бирүчеләр: юридик һәм физик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

Гариза бирүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә шәхесен таныклаучы документлар һәм ышаныч кәгазе нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүченең билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) профильләштерү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объеклары яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәте Комитетның Биотөрлелек бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе аша һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны (алга таба – КФҮ) аша күрсәтелә.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату биргән очракта, КФҮ соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлегенә ия.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

Төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының аерым саклана торган төбәк әһәмиятендәге табигый территория чикләрендә («Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә (алга таба – туры килү турында хәбәрнамә) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының аерым саклана торган төбәк әһәмиятендәге табигый территория чикләрендә («Аеруча саклана торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килмәве турында хәбәрнамә (алга таба – туры килмәү турында хәбәрнамә) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын алу.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына http://uslugi.tatarstan.ru (алга таба –Республика порталы) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталына (http://gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал) җибәрелә. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу башка мәгълүмати

системаларда теркәлми.

Гариза бирүченең теләге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук Комитетта яки КФҮдә Комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәре мөһере һәм имзасы белән таныкланган кәгазьдә басылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамәне юллау процедурасын гамәлгә ашыру вакыты шәхси торак төзелеше яки бакча йортын төзү яки үзгәртеп кору тәмамлануы турында хәбәрнамә килгән көннән җиде эш көне тәшкил итә (алга таба – төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә).

Хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны һәм кушып бирелә торган документларны Комитетка тапшыру Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә. Төзелеш тәмамлануы турында хәбәрнамәне юллау яки кире кайтару процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның КФҮдә булган вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталында, Бердәм порталда электрон кабинетка) җибәрү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу вакыты дәвамында алырга хокуклы.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Республика Порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, гариза бирүче шәхсән үзе тапшыра торган документлар:

1. «Шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларын төзү һәм үзгәртеп кору өчен кирәкле хәбәрнамәләр формаларын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш

Министрлыгының 591/пр номерлы боерыгы) белән расланган форма буенча төзелешне тәмамлау хакында хәбәрнамә (гариза) (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

2. Төзелешне тәмамлау турында хәбәрнамәгә (гаризага) түбәндәге документларны теркәргә кирәк:

1) хәбәрнамә төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

2) төзүче чит ил юридик заты булган очракта, юридик затны чит дәүләт законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турында документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе;

3) шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының техник планы;

4) шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты төзелгән яки реконструкцияләнгән җир кишәрлеге гомуми өлешле милек хокукында яки арендатор ягында күп санлы затлар белән аренда хокукында ике һәм аннан да күбрәк гражданга караган очракта, җир кишәрлегенең хокук ияләре арасында төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше объектларына яки бакча йортына гомуми өлешле милек хокукында аларның өлешен билгеләү турында билгеләү турында төзелгән килешү.

5) Гариза бирүченең яисә Гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә). Республика порталы яки Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне раслый торган документтан белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында хисап язмасын раслаганда тикшерелә;

Дәүләт хезмәтен алу өчен төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) бланкын гариза бирүче Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә һәм аңа теркәп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазьдә һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-63 – ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазь чыганакларда һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Төзелеш тәмамлануы турында хәбәрнамә (гариза) биргәндә, гариза бирүчегә КФҮ дән гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы белән расписка бирелә;

3) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада.

Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, гариза бирүче төзелеш тәмамлану турында

хәбәрнамәне (гаризаны) тапшырган көнне, Республика порталда, Бердәм порталда шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәнең (гаризаның) җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала, анда теркәү номеры һәм төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) бирү датасы күрсәтелә.

Гариза бирүчеләр төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук хисап язмасын стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) көчәйтелгән квалифицияле электрон имза белән имзалыйлар.

Республика порталы, Бердәм портал аша сорату биргәндә, гариза бирүче документларның электрон үрнәкләрен яисә мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документлар тапшыра.

Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын бирү өчен Гариза бирүче Комитетка туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын алуы турында әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендә язма гариза җибәрә.

Гариза бирүченең шәхесен билгеләү Россия Федерациясе гражданы паспортын яки шәхесен таныклый торган башка документ күрсәтү юлы белән шәхсән кабул итү барышында Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның $14^1$ статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, Комитетта, КФҮ дә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар таләп ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) вәкаләтләренә дәүләт

хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган;

2) төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) формасында, шул исәптән төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәнең интерактив формасында, Республика порталында, Бердәм порталда кырларны тулысынча тутырмау;

3) тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслаучы документ; Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган тәртиптә текстны төзәтү һәм бетерү бар;

5) электрон рәвештә тәкъдим ителгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар;

6) төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар, аларны бирү форматларына карата таләпләрне бозып, электрон формада бирелгән һәм (яки) укылмый;

7) 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

1. Туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрү өчен нигезләр:

а) төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларның параметрлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ШтК) 55 статьясындагы 19 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп коруның иң чик параметрларына яки РФ ШтК һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килми;

б) шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәте мондый объектның яки йортның планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәгә кушымта булып тора торган тышкы кыяфәте тасвирламасына яисә планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән типлаштырылган архитектура карарына туры килми яисә төзүчегә планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве турында һәм (яисә), федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки үзгәртеп кору очрагында, РФ ШтК 51[1] статьясындагы 10 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән нигез буенча җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштырырга ярамау турында хәбәрнамә җибәрелгән;

в) төзелгән яки үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектыннан рөхсәт ителгән файдалану төре планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә туры килми;

г) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә кергән көнгә Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә туры килми, әлеге чикләүләр капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата кабул ителгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карарда каралган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш.

2. төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне кире кайтару өчен нигезләр:

а) төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләрнең булмавы:

төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны, шәхесне раслый торган документ реквизитлары (физик зат өчен);

төзүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве турындагы язманың Дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш;

җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), җир кишәрлегенең адресы яки урнашкан урыны тасвирламасы;

төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның (андый затлар булганда) хокуклары турында белешмәләр;

җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын (шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын) рөхсәт ителгән файдалану төре турында белешмәләр;

шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен билгеләнмәгәнлеге турында белешмәләр;

төзүче белән элемтәгә керер өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше объектының яки бакча йортының параметрлары турындаы;

хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасын түләү турында;

төзүчегә хәбәрнамә җибәрү ысулы турында;

б) төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәгә әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документлар беркетелмәгән;

в) төзелешне тәмамлау турында хәбәрнамә планлаштырылган төзелеш турында аның нигезендә шәхси торак яисә бакча йорты төзелеше яисә үзгәртеп кору башкарылган хәбәрнамә кергән көннән соң ун ел үткәч килгән булса, яисә планлаштырыла торган мондый шәхси торак объектын яисә бакча йортын төзү турында хәбәрнамә элек җибәрелмәгән (шул исәптән, төзүчегә РФ ШтК $51^{1}$ статьясындагы 6 өлеше нигезендә кире кайтарылган) булса.

Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә һәм аңа кушып бирелгән документлар гариза бирүчегә кире кайтарыла, һәм хәбәрнамә җибәрелмәгән дип санала.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтенә гариза бирүче аерым категория өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү вакыты

Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) алынган көнне.

Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза), КФҮдән кергән көнне, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Электрон рәвештә Республика порталына, Бердәм порталга (техник мөмкинлек булган очракта) килгән төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза), Республика Порталында, Бердәм порталда запросларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кергән көнне теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бинада һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (урынында)дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре белән мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөртүче этләрдән файдаланучыларга, бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

биналарга һәм бүлмәләргә, шулай ук аларга күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыксыз керү шартлары;

территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, биналарга һәм бүлмәгә керү һәм чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска кулланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны биналарда һәм бүлмәләрдә озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларның хезмәт күрсәтү урыннарына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып, бинада һәм бүлмәләрдә тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктале шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемне кертү

йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда бинага һәм бүлмәгә кертергә рөхсәт итү;

Комитетның парковкасында I, II төркем инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларын түләүсез куеп тору өчен урыннарның кимендә 10 проценты (ләкин бер урыннан да ким булмаган күләмдә) бүлеп бирелә. Әлеге пунктта күрсәтелгән парковка урыннарын, юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган очраклардан тыш, башка транспорт чаралары биләмәскә тиеш;

Комитетның хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

2.13. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкин булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәттән файдаланырга комачаулый торган, инвалидлар өчен биналардан файдалану уңайлылыгын тәэмин итүгә бәйле булмаган башка каршылыкларны җиңеп чыгуда Комитет хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү;

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документларны кабул итү һәм карау вакытлары үтәлү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакыты үтәлү;

Комитет белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

гариза бирүченең Комитет белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:

турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда – икедән дә артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон почта аша да, бердән артык түгел.

Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы соратып алу составында күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Комитетта, Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетында, КФҮдә алырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.3. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә консультация бирүне, документларны кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Комитет һәм МФЦ арасындагы хезмәттәшлек тәртибе – Комитет һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлеге тәртибе КФҮнең эше регламенты белән җайга салына.

2.14.4. Гариза бирүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары белән билгеләнгән электрон документ рәвешендә гариза җибәрә ала, ул гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрдән, шул исәптән бердәм һәм конфиденциаль мәгълүмат, шулай ук арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматын электрон рәвештә җибәрү һәм алу мөмкинлеген тәэмин итә торган «Интернет» челтәреннән, шулай ук Республика порталыннан яки Бердәм порталдан файдаланып, гади электрон имза кулланып, 63-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә тапшырыла.

Комитетка, Төбәк порталыннан яки Бердәм порталдан файдаланып, электрон документ рәвешендә кергән гаризаны теркәү, шулай ук гариза бирүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Комитетка тапшыру датасын күрсәтеп, аның гаризасын алу турында мәгълүмат булган электрон хәбәрнамә формалаштыру һәм җибәрү Комитетка гариза кергән көнне автомат режимда башкарыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерү, аларны теркәү, карау, дәүләт

хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында карар кабул итү әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.14.6. Гариза бирүчегә күрсәтелә торган дәүләт хезмәте турында мәгълүматны Республика порталыннан, Бердәм порталдан алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Административ процедуралар үтәлешенең составы, эзлеклелеге һәм вакыты

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән гариза язу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) туры килү турында хәбәрнамә (туры килмәү турында хәбәрнамә) җибәрү яки төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару:

а) Комитетка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән рәсми почтага ojm@tatar.ru электрон документ формасында), КФҮдән, Төбәк порталыннан, Бердәм порталдан алынган документларны һәм төзелешне тәмамлау турында хәбәрнамәне (гаризаны) кабул итү һәм теркәү;

б) кергән гаризаларны, документларны карау һәм туры килү турында хәбәрнамә әзерләү;

в) гариза бирүчегә туры килү турында хәбәрнамә җибәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

3) техник хатаны төзәтү:

а) техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта);

в) яңадан рәсмиләштерелгән туры килү турында хәбәрнамә (туры килмәү турында хәбәрнамә) әзерләү;

в) гариза бирүчегә яңадан рәсмиләштерелгән туры килү турында хәбәрнамә (туры килмәү турында хәбәрнамә) бирү;

4) туры килү турында хәбәрнамәнең (туры килмәү турында хәбәрнамәнең) дубликатын әзерләү, бирү:

а) туры килү турында хәбәрнамәнең (туры килмәү турында хәбәрнамәнең) дубликатын бирү хакында гаризаны кабул итү һәм теркәү;

в) туры килү турында хәбәрнамәнең (туры килмәү турында хәбәрнамәнең) дубликатын әзерләү;

в) гариза бирүчегә туры килү турында хәбәрнамәнең (туры килмәү турында хәбәрнамәнең) дубликатын бирү;

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) язу өлешендә ярдәм күрсәтү;

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен

мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Бүлек белгече, кирәк булганда, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм итә.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе, шул исәптән төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) рәсмиләштерү тәртибе турында консультация алу өчен, Комитетка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша электрон хәбәр рәвешендә (e-mail: ojm@tatar.ru), кәгазьдә почта аша, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе (http://ojm.tatarstan.ru) аша мөрәҗәгать итә.

Гариза бирүче КФҮгә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка сораулар буенча мәгълүмат бирә һәм, кирәк булганда, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә бланкын тутыруда ярдәм итә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны күпфункцияле үзәк сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru) ирекле рәвештә алырга мөмкин.

Шулай ук гариза бирүче Республика порталында, Бердәм порталда Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация оештыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Туры килү турында хәбәрнамә (туры килмәү турында хәбәрнамә) җибәрү яки төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне карамыйча кире кайтару:

3.3.1. Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә (гариза) электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизация үтә;

Республика Порталында, Бердәм порталда электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык

турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне (гаризаны) КФҮ аша биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә КФҮгә документлар тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮ эше регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, КФҮ белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, КФҮ белгече кабул ителгән һәм теркәлгән документларны КФҮнең эш Регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Комитет һәм МФЦ арасындагы хезмәттәшлек тәртибе – Комитет һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлеге тәртибе КФҮ нең эше регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар КФҮ эше регламентында һәм КФҮ белән Комитет арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза яки документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә бирелгәннәрен һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның комплектлылыгын, электрон үрнәкләренең укылышын тикшерә;

Республика порталына, Бердәм порталга мөрәҗәгать итеп, электрон имзаның чынбарлык шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның

электрон образлары тапшырылган очракта);

гариза бирүченең вәкаләтле заты буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү;

документларны кабул итү датасы турында тамга, бирелгән керү номеры белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү (почта аша гариза биргәндә).

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече Төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәләрне теркәү журналына (алга таба – Журнал) мәгълүмат кертә.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

Гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (Комитетка керү датасы)

гариза бирүченең исеме;

документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәнең вәкаләтле вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объект исеме һәм кергән документларның бит (папкалар, тартмалар һ. б.) саны;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү датасы.

Журнал әлеге Регламентка 7 нче кушымта нигезендә кульязма һәм электрон формада алып барыла.

Әлеге Регламентта күрсәтелгән процедураны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитетка гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.3.3. Кергән гаризаларны, документларны карау һәм туры килү турында хәбәрнамә әзерләү.

1. Кергән гаризаларны, теркәлгән документларны карау. Бүлек белгече документларның әлеге Регламентның 2.6.1 пункты таләпләренә туры килү-килмәве предметына тикшерә;

төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты параметрларының төзелеш тәмамлану турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә керү датасына гамәлдәге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документация белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт

ителгән төзү, үзгәртеп коруның иң чик параметрларына һәм РФ ШтК, башка федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын карау юлы белән шәхси торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәтенең планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәгә кушымта булып торучы шундый объект яки йортның тышкы кыяфәте тасвирламасына яисә, шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын федераль яки, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә төзегән яки үзгәртеп корган очракта, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән типлаштырылган архитектура карарына туры килүен тикшерә;

шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектыннан рөхсәт ителгән файдалану төренең планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән рөхсәт ителгән куллану төренә туры килүен тикшерә;

Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә, төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә кергән көнгә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыру мөмкинлеген тикшерә, әгәр күрсәтелгән чикләүләр территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында төзү, үзгәртеп кору планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектына карата кабул ителгән карарда каралган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каралган гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар.

2. Бүлек белгече гариза бирүчедән кергән документлар нигезендә түбәндәгеләрне башкара:

туры килү турында хәбәрнамә әзерли;

килештерү өчен Бүлек башлыгына туры килү-килмәү турында хәбәрнамә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, һәм шул ук вакытта гаризада төзелешкә рөхсәтне электрон рәвештә алу күрсәтелгән булса, Бүлек белгече законнарда билгеләнгән форма буенча Рөхсәт кәгазен электрон рәвештә әзерли.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән туры килү турында хәбәрнамә.

3. Туры килү турында хәбәрнамәгә карата кисәтүләр булмаган очракта, Бүлек башлыгы аны килештерә һәм Комитет рәисенә имзага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза салырга җибәрелгән туры

килү турында хәбәрнамә.

4. Туры килү турында хәбәрнамәгә кисәтүләр булмаган очракта, Комитет рәисе туры килү турында хәбәрнамәгә кул куя һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килү турында имзаланган гариза.

5. Туры килү турындагы хәбәрнамәгә карата кисәтүләр булган очракта, Комитет рәисе Бүлек белгеченә эшләп бетерү кирәклеге турында резолюция белән документларны кире кайтара.

Эшләп бетерелгән туры килү турында хәбәрнамә Бүлек белгече тарафыннан Комитет рәисенә тапшырыла.

Комитет рәисе туры килү турында хәбәрнамәгә кул куя һәм аны бүлеккә җибәрә.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен Электрон формада алу турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән электрон документ формасындагы туры килү турында хәбәрнамәне имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламент белән каралган алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килү турында имзаланган гариза.

3.3.4. Туры килү турында хәбәрнамә җибәрү.

1. Бүлек белгече Бирелгән хәбәрнамәләр реестрында (әлеге Регламентка 8 нче кушымта) туры килү турында хәбәрнамәне терки һәм гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитет рәисе тарафыннан туры килү турындагы хәбәрнамәгә кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән Туры килү турында хәбәрнамәләр реестрында теркәлгән туры килү турында хәбәрнамә,

2. Бүлек белгече гариза бирүчегә мөрәҗәгать итү көнендә хәбәрнамә алу турында имза белән туры килү турында рәсмиләштерелгән хәбәрнамә бирә.

Гариза бирүче Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне яисә, гариза бирүче Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, Комитет рәисе тарафыннан туры килү-килмәү турында хәбәрнамәләргә имза салынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән туры килү турында хәбәрнамә яисә, Республика порталын, Бердәм порталны кулланып, гариза бирүчегә җибәрелгән туры килү турында хәбәрнамә.

3. Гариза бирүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә. Гариза бирүче таләбе буенча

кәгазьдә электрон документның нөсхәсе белән бергә аңа электрон документның нөсхәсе алынма чыганакта бирелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне КФҮ эшчәнлеге регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә башкарыла.

3.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

1. Туры килмәү турында хәбәрнамә әлеге Регламентның 2.8 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда әзерләнә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, әлеге Регламентның 3.3.3 пунктының 1 пунктчасында каралган процедура тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: туры килмәү турында хәбәрнамә.

2. Әлеге Регламентның 2.8 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне һәм аңа кушып бирелә торган документларны, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, кире кайтара. Бу очракта төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамә җибәрелмәгән дип санала.

Гариза бирүче Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура төзелеш тәмамлануы турында хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә төзелеш тәмамлану турында хәбәрнамәне һәм аңа кушып бирелә торган документларны, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, карап тикшермичә кире кайтару.

3.4. Техник хатаны төзәтү

Туры килү турындагы хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү гариза бирүчегә бирелгән белдерүдә җибәрелгән техник хаталарны (язудагы хаталарны, басмадагы хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) юкка чыгару белән бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Туры килү турындагы хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү, гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы туры килү-килмәү турындагы хәбәрнамәне кушып, теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

документларны кабул итү датасы турында тамга, бирелгән керү номеры белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

3.4.2. Бүлек белгече:

туры килү турында хәбәрнамәне кабат рәсмиләштерә;

туры килү турында хәбәрнамә һәм гариза бирүчегә туры килү турында

хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү хакында хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән гариза бирүчегә туры килү турында хәбәрнамә һәм хат проекты.

3.4.3. Бүлек җитәкчесе әзерләнгән туры килү турындагы хәбәрнамәнең дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имзаларга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына туры килү турында хәбәрнамә һәм хат проекты килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза салырга җибәрелгән туры килү турында хәбәрнамәләр һәм хат проекты.

3.4.4. Комитет рәисе кушып бирелә торган туры килү турында хәбәрнамә белән хат проектын имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган хат һәм имзаланган туры килү турында хәбәрнамә.

3.4.5. Бүлек белгече Комитет рәисе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны терки, ул туры килү турында хәбәрнамә белән бергә гариза бирүчегә яки аның ышанычлы затына (ышаныч кәгазе булган очракта) расписка белән җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче яки аның ышанычлы заты килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән хат һәм техник хатасы төзәтелгән туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамә.

3.5. Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын алу.

3.5.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

документларны кабул итү датасы турында тамга, бирелгән керү номеры белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

3.5.2. Бүлек белгече:

Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын әзерли, туры килү турында хәрнамә дубликатының алгы ягында «Дубликат» штампы суга;

Гариза бирүчегә туры килү турында хәбәрнамә дубликатын әзерләү турында хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә башкару өчен гариза җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән

туры килү турында хәбәрнамәнең әзерләнгән дубликаты.

3.5.3. Бүлек җитәкчесе әзерләнгән туры килү турындагы хәбәрнамә дубликатының дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имзаларга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына туры килү турында хәбәрнамә дубликаты һәм хат проекты килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза салырга җибәрелгән туры килү турында хәбәрнамәләр һәм хат проекты.

3.5.4. Комитет рәисе кушып бирелә торган туры килү турында хәбәрнамә дубликаты белән хат проектын имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән хат проекты, туры килү турында хәбәрнамәнең дубликаты.

3.5.5. Бүлек белгече Комитет рәисе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны терки, ул туры килү турында хәбәрнамә дубликаты белән бергә гариза бирүчегә яки аның ышанычлы затына (ышаныч кәгазе булган очракта) расписка белән бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче яки аның ышанычлы заты килгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән хат һәм туры килү турында хәбәрнамә дубликаты.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәвен һәм башкаруын, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәге тикшерүләрне үткәрү керә:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләр бирү вакытын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрү периоды планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга ия (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча).

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең

хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Административ регламентны башкаруны гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләрнең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә Комитетның дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Комитетка шикаять бирергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Комитет карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр – КФҮ җитәкчесенә, КФҮнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) – КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Комитетның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу;

8) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктатып тору нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, Комитетның рәсми сайты (http://ojm.tatarstan.ru), Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын (http://mfc16.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталын (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru) кулланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр яки гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адрес(-лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең , КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән гариза бирүче килешми торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять аның кергән көненнән соң килә торган эш көненнән дә соңга

калмыйча теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта шикаять белдерелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, йә дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы белән расланган

Кемгә:

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

Почта адресы: ________________

______________________________

______________________________

Электрон почта адресы (булганда):

______________________________

______________________________

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә

«__» ____________ 20__ ел №______________________

Шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә үзгәртеп кору тәмамлану турында хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) карау нәтиҗәләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе турында хәбәр итәбез

җибәрелгән ______________________________________________________

(хәбәрнамә җибәрү датасы)

теркәлгән ______________________________________________________

(хәбәрнамәне теркәү датасы һәм номеры)

______________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән)

______________________________________________________________________________,

______________________________________________________________________________

(шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты)

хәбәрнамәдә күрсәтелгән һәм җир кишәрлегендә урнашкан

______________________________________________________________________________

(җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), җир кишәрлегенең адресы яки

______________________________________________________________________________

урнашу урыны тасвирламасы)

| ______________________________ | ____________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (федераль башкарма хакимият органының, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органының, җирле үзидарә органының төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләте булган вәкаләтле вәкиленең вазыйфасы) | (имза) | (имзаның расшифровкасы) |

М.У.

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Форма**

Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы белән расланган

Кемгә:

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

______________________________________

Почта адресы: ______________________

______________________________________

______________________________________

Электрон почта адресы (булганда):

______________________________________

______________________________________

**Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килмәве турында хәбәрнамә**

«__» ____________ 20__ ел ________________/_____________________/

Шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты төзелеше яисә үзгәртеп кору тәмамлану турында хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә), карау нәтиҗәләре буенча

җибәрелгән _______________________________________________________________

(хәбәрнамәне җибәрү датасы)

теркәлгән _________________________________________________________

(хәбәрнамәне теркәү датасы һәм номеры)

_________________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән)

_________________________________________________________________________

(шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты)
хәбәрнамәдә күрсәтелгән һәм җир кишәрлегендә урнашкан

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), җир кишәрлегенең адресы яки урнашу урыны тасвирламасы)

шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә түбәндәге нигезләр буенча

1. ________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(төзелгән яисә үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 19 өлешенең 1 пунктында (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2005, № 1, 16 ст.; 2018, № 32, 5135 ст.) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзү, үзгәртеп коруның иң чик параметрларына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килмәве турында белешмәләр)

2. ________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(шәхси торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәте планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яисә бакча йортын төзү яки үзгәртеп кору турындагы хәбәрнамәгә кушымта булып торучы (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) шундый объект яки йортның тышкы кыяфәте тасвирламасына яисә планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән типлаштырылган архитектура карарына туры килмәү турында мәгълүматлар; яки төзүчегә, планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрелүе һәм (яки), шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын федераль яки, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек чикләрендә төзегән яки үзгәртеп корган очракта, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 статьясындагы 10 өлешенең 4 пунктында (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2005, № 1, 16 статья; 2018, № 32, 5133, 5135 статьялар) күрсәтелгән нигез буенча җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруга рөхсәт ителмәү турында мәгълүматлар)

3. ________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(төзелгән яки үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектыннан файдалану төренең планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объектыннан яки бакча йортыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә туры килмәве турында белешмәләр)

4. ________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын хәбәрнамә килгән датага Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары билгеләгән чикләүләр нигезендә урнаштыруга юл куймау турында белешмәләр, күрсәтелгән чикләүләр территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яисә үзгәртү турында капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата кабул ителгән карарда каралган һәм мондый капиталь төзелеш объекты файдалануга тапшырылмаган очраклардан тыш)

туры килмәү турында хәбәр итәбез.

| ______________________________ | ______________ | ______________ |
| --- | --- | --- |
| (федераль башкарма хакимият органының, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органының, җирле үзидарә органының төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләте булган вәкаләтле вәкилнең вазыйфасы) | (имза) | (имзаның расшифровкасы) |

М.У.

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

Кемгә: ______________________________
(физик затның, шәхси эшкуарның
______________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме
______________________________
(булса) /
______________________________
юридик затның исеме

Баш тарту турында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты
______________________________________________________________
физик затның торган урыны, Ф.И.А. (булса)
______________________________________________________________
паспорт белешмәләре, теркәлү адресы)
______________________________________________________________

дәүләт хезмәте күрсәтүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә
(кирәклесенең астына сызарга)
______________________________________________________________
(дәүләт хезмәте атамасы)

Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________

______________________
_

| | | |
|---|---|---|
| (вазыйфасы) | ______________ (имза) | ______________________ (Ф.И.А (булса)) |

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

**Форма**

Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы белән расланган

Шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзүне яки үзгәртеп коруны тәмамлау турында хәбәрнамә

«______»____________20____ ел

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(федераль башкарма хакимият органының, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органының, җирле үзидарә органының төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле вәкилнең исеме)

1. Төзүче турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Төзүче физик зат булса, физик зат турында мәгълүмат: | |
| 1.1.1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта); | |
| 1.1.2 | Яшәү урыны | |
| 1.1.3 | Шәхесне раслый торган документ реквизитлары | |
| 1.2 | Төзүче юридик зат булса, юридик зат турында белешмәләр: | |
| 1.2.1 | Атамасы | |
| 1.2.2 | Урнашкан урыны | |
| 1.2.3 | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры, гариза бирүче чит ил юридик заты булган очрактан тыш | |
| 1.2.4 | Салым түләүченең идентификация номеры, гариза бирүче чит ил юридик | |

| | | |
|---|---|---|
| | заты булган очрактан тыш | |

## 2. Җир кишәрлеге турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Җир кишәрлегенең кадастр номеры (булганда) | |
| 2.2 | Җир кишәрлегенең адресы яки урнашкан урыны тасвирламасы | |
| 2.3 | Төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр (хокук билгели торган документлар) | |
| 2.4 | Җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары булу турында белешмәләр (булганда) | |
| 2.5 | Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре турында белешмәләр | |

## 3. Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 3.1 | Капиталь төзелеш объектын (шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты) рөхсәт ителгән файдалану төре турында белешмәләр | |
| 3.2 | Хәбәрнамә бирү максаты (төзелеш яки үзгәртеп кору) | |
| 3.3 | Параметрлары турында мәгълүмат: | |
| 3.3.1 | Җир өсте катлары саны | |
| 3.3.2 | Биеклеге | |
| 3.3.3 | Җир кишәрлеге чикләреннән чигенүләр турында белешмәләр | |
| 3.3.4 | Төзелеш мәйданы | |

## 4. Җир кишәрлегендә төзелгән яки үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының схематик сурәте

Элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы:

______________________________________________________________

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча

йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килмәве турында хәбәрнамәне түбәндәге ысул белән җибәрергә

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(почта адресына һәм (яки) электрон почтага яисә Башкарма хакимиятнең федераль органында, Россия Федерациясе субъекты Башкарма хакимияте органында яисә җирле үзидарә органында төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле вәкилгә җибәрү юлы белән, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша да)

Әлеге хәбәрнамә белән ______________________________

(шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты)

мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен, шулай ук хокукларны дәүләт теркәвенә алган өчен дәүләт пошлинасын түләү өчен билгеләнмәгән икәнлеген раслыйм

______________________________________________________________________

(түләү документы реквизитлары)

Әлеге хәбәрнамә белән мин, ______________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________________________________________________________

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм (әгәр төзүче физик зат булса).

____________________ ____________ ____________________

(төзүче юридик зат булган очракта, вазыйфасы) (имза) (имзаның расшифровкасы)

М.У.
(булганда)

Әлеге хәбәрнамәгә кушымта итеп бирелә:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар
(дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме)
буенча дәүләт комитетына
кемнән: ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),
___________________________________________
паспорт белешмәләре / гариза бирүче исеме)
___________________________________________
(гражданның индивидуаль шәхси хисабының иминият
___________________________________________
номеры – СНИЛС (физик затлар өчен),
___________________________________________
ИНН; житәкченең Ф.И.А. (булганда);
___________________________________________
банк реквизитлары (банкның атамасы, р/с, к/с, БИК)
___________________________________________
почта һәм юридик адреслар, телефон;
___________________________________________
электрон почта адресы (теләк буенча)

## Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын бирү турында гариза

Капиталь төзелеш объектының туры килүе турында хәбәрнамәнең дубликатын бирүегезне сорыйм: ___________________________________________
файдалануга тапшыруга рөхсәт нигезендә
___________________________________________
капиталь төзелеш объектының (этап) атамасы,
___________________________________________
Бердәм дәүләт реестрында исәпкә алынган реконструкцияләнә торган объектка
___________________________________________
карата кадастр номеры

урнашкан адресы: ___________________________________________
___________________________________________
(дәүләт адреслы реестры нигезендә капиталь төзелеш объектының адресы;

___

дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органының капиталь төзелеш объектына адресны бирү, үзгәртү турында адреслар бирүгә вәкаләтле актының реквизитларын күрсәтеп, линия объектлары өчен – Россия Федерациясе субъект(-лар)ы атамасы рәвешендә урнашкан урыны күрсәтелә, муниципаль берәмлек(-ләр) төре һәм атамасы рәвешендә күрсәтелә, шулай ук берәмлекләр рәвешендә, әгәр линияле объект яки аның өлеше (өлешләре) торак пункт чикләрендә урнашкан булса)

Капиталь төзелеш объектының туры килүе турында хәбәрнамә реквизитлары (датасы, номеры): ______________________________________________

Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын бирү зарурлыгы түбәндәге шартларга бәйле:

___

Туры килү турында хәбәрнамәнең дубликатын кәгазьдә яки электрон документ формасында әзерләвегезне сорыйм.

(кирәкмәгәнне сызарга)

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (вазыйфасы) | (имза) | (Ф.И.А (булганда)) |

«____»______________________20__ ел

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар
(дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме)
буенча дәүләт комитетына
кемнән: ______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),
______________________________
паспорт белешмәләре / гариза бирүче исеме)
______________________________
(гражданның индивидуаль шәхси хисабының иминият
______________________________
номеры – СНИЛС (физик затлар өчен),
______________________________
ИНН; җитәкченең Ф.И.А. (булганда);
______________________________
банк реквизитлары (банкның атамасы, р/с, к/с, БИК)
______________________________
почта һәм юридик адреслар, телефон;
______________________________
электрон почта адресы (теләк буенча)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
______________________________________________________________
(хезмәтнең атамасы)
Язылган: ______________________________________________________
______________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________________
______________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.

В случае принятия решения об отклонении заявления об исправлении технической ошибки прошу направить такое решение:

электрон документны E-mail адресына __________ җибәрү юлы белән;

______________________________________________________________________________;

кәгазьдә почта белән түбәндәге адрес буенча җибәреп:

______________________________________________________________________________.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм.

Документы (копии документов), приложенные к заявлению, соответствуют требованиям, установленным законодательством Российской Федерации, на момент представления заявления эти документы действительны и содержат достоверные сведения.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ____________________ | (__________________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А (булганда)) |

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Форма

Шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзүне яки үзгәртеп коруны тәмамлау турында хәбәрнамәләрне теркәү журналы

| т/б № | Гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (документларны теркәү датасы) | Гариза бирүченең исеме | Объектның исеме | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү датасы | Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү датасы | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган зат имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Форма

Туры килү (туры килмәү) турында бирелгән хәбәрнамәләрнең реестры

| т/б № | Гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру турында мәгълүмат (кергән документның номеры һәм датасы) | Гариза бирүче турында мәгълүмат | Объектның исеме, адресы | Туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамәнең датасы һәм номеры | Туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамә алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Төзелгән яисә реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис | 211-66-94 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | 211-75-06 | Ramil.Sharafutdinov0@tatar.ru |
| Идарә Башлыгы | 211-70-78 | Rinat.Chispyakov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы: | 211-68-62 | Roza.Ahmetsafina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |